КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 3 август г.Казань № 671

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Шәхси милектә булган җир кишәрлекләре мәйданын аларны Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләре яки дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән яңадан бүлү нәтиҗәсендә арттырган өчен түләү күләмен билгеләү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 19 март, 168 нче карары белән расланган Шәхси милектә булган җир кишәрлекләре мәйданын аларны Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләре яки дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән яңадан бүлү нәтиҗәсендә арттырган өчен түләү күләмен билгеләү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Шәхси милектә булган җир кишәрлекләре мәйданын аларны Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләре яки дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән яңадан бүлү нәтиҗәсендә арттырган өчен түләү күләмен билгеләү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 19 март, 168 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 3 август, 638 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Шәхси милектә булган җир кишәрлекләре мәйданын аларны Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләре яки дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән яңадан бүлү нәтиҗәсендә арттырган өчен

түләү күләмен билгеләү тәртибенә, 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3. Түләү күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә дип билгеләргә (әлеге Тәртипнең 4 пунктында каралган очрактан тыш):

$$Р_п = (П_2 – П_1) \times УПКС_{чс},$$

монда:

$Р_п$ – түләү күләме;

$П_2$ – яңача бүлү турындагы килешү нигезендә, шәхси милектә булган җир кишәрлеге мәйданы;

$П_1$ – яңача бүлү турында килешү төзелгәнче, шәхси милектә булган башлангыч җир кишәрлеге мәйданы;

$УПКС_{чс}$ – шәхси милектәге җир кишәрлеге өчен кадастр бәясенең чагыштырма күрсәткече, аның мәйданы яңадан бүлү нәтиҗәсендә арта. $УПКС_{чс}$ аның мәйданына җир кишәрлегенең кадастр бәясен бүлү юлы белән билгеләнә (сум/кв. метр).».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин